| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Девятернинского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Девәтернә авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20.12.2022 Девәтернә авылы № 26-2

Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары исемлеген, җирле әһәмияттәге гомуми файдалануда булмаган автомобиль юллары исемлеген раслау өлешендә җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге буенча вәкаләтләренең бер өлешен Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшыру турында

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясындагы 9 пункты, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 3 өлешенең 17 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары исемлеген, җирле әһәмияттәге гомуми файдалануда булмаган автомобиль юллары исемлеген раслау өлешендә җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге буенча вәкаләтләренең бер өлешен Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшырырга.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль район Советына тәкъдим итәргә: